ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, ,
423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Яңа урам, 4в
йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 6** **29.01.2026 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Ак Юл торак пунктында 2026 елда гражданнар җыенының 2025 елның 03 декабрендәге 14 санлы карарын,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Тарлау торак пунктында 2026 елда гражданнар җыенының 2025 елның 03 декабрендәге 16 санлы карарын,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Екатериновка торак пунктында 2026 елда гражданнар җыенының 2025 елның 03 декабрендәге 18 санлы карарын,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Яссы Тугай торак пунктында 2026 елда гражданнар җыенының 2025 елның 03 декабрендәге 20 санлы карарын,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Алабакүл торак пунктында 2026 елда гражданнар җыенының 2025 елның 03 декабрендәге 22 санлы карарын,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Димтамак торак пунктында 2026 елда гражданнар җыенының 2025 елның 03 декабрендәге 24 санлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru/ һәм "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" челтәр басмасында Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru (2013 елның 17 декабрендәге Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы

муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталында түбәндәге адресы буенча http://jutaza.tatarstan.ru / урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов

Димтамак авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2026 елның “29”
гыйнварындагы 6 санлы карарына 1 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган һәр граждан, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләреннән, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш 2026 елның 22 гыйнварыннан 2026 елның 28 мартына кадәр үзара салым акчалары түләүне башкара.

3. Түбәндәге очракларда нигезле сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт тормау,

б) авыру,

гражданнарга түләүне гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерү юлы белән, шулай ук кул куеп тапшыру, я почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртү) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша акча күчерү юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын акча керү турындагы касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

8. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгән очракта, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның “29” гыйнварындагы 6 санлы карарына
2 нче кушымта

Димтамак авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адресы: ____________________________________________________________
_____________________________________________ нигезендә
____________________Сезгә 2026 елның “___”_____________кадәр үзара салым түләү буенча узган җыен чараларын гамәлгә ашыру буенча түбәндәге реквизитлар буенча бер тапкыр түләнә торган сумма күчерергә кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү

Җитәкче ________________________________________________________
М.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Димтамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ __________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
_________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адресы: __________________________________________________________________
«__» ________________ 20__ елны __________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.